**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлегенең Норлат авылында гражданнар җыены карары**

14 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Норлат авыл җирлегенең Норлат авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Норлат авыл җирлегенең Норлат авылында авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 400 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Норлат авылында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзүне, ремонтлауны, карап тотуны?»

3. Җыен нәтиҗәләрен Норлат авыл җирлегенең Норлат авылында авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Норлат авыл җирлеге башлыгы _________ М.Х.Закиров

Гражданнар җыены секретаре _________ Д.М.Хәмидуллина